ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НОВОКЫРЛАЙСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д. 3, с.Новый Кырлай,
Арский муниципальный район, 422035

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА КЫРЛАЙ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Үзәк урам, 3 йорт, Яңа Кырлай авылы,
Арча муниципаль районы, 422035

Тел. (84366)56-7-32, факс (84366)56-7-34. E-mail: Nkrl.Ars@tatar.ru

# КАРАР

**« 08 » июнь 2016 ел** **№ 1**

**Яңа Кырлай авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында Яңа Кырлай авыл җирлеге Советы карары проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында**

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Шәһәр төзелеше Кодексы, Яңа Кырлай авыл җирлеге уставы, Яңа Кырлай авыл җирлегендә Яңа Кырлай авыл җирлегенең 19.10.2009 №25 карары белән расланган гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмә нигезендә, Яңа Кырлай авыл җирлеге халкының муниципаль хокукый актлар проектлары буенча фикер алышуда катнашуга хокукын тәэмин итү максатларында карар бирәм:

**1.** Яңа Кырлай авыл җирлеге Советының 2012 елның 29 ноябрендәге 22 номерлы карары белән расланган Яңа Кырлай авыл җирлегенең Җир куллану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында карар проекты буенча гавами тыңлауларын 15.08.2016 елга билгеләргә.

2. Яңа Кырлай авыл җирлеге Советының 2012 елның 29 ноябрендәге 22 номерлы карары белән расланган Яңа Кырлай авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында карар проекты буенча гавами тыңлауларны 10 сәгаттә ТР, Арча районы, Яңа Кырлай авылы, Үзәк ур., 3 йорт адресы буенча уздырырга.

3. Яңа Кырлай авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә карата тәкъдим ителә торган үзгәрешләр буенча гражданнарның тәкъдимнәре, искәрмәләре һәм гавами тыңлауларда катнашуга гаризалары язмача рәвештә 16 сәгатькә кадәр җибәрелә дип билгеләргә. 11.08.2016нчы адрес буенча: ТР, Арча районы, Арча районы, Яңа Кырлай авылы, Үзәк тур., 3йорт., тел. 56-7-34.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районы рәсми сайтында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Яңа Кырлай авыл җирлеге башлыгы Г.Г.Сәфәров

ПРОЕКТ

**Яңа Кырлай авыл җирлеге Советы карары**

**«Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Яңа Кырлай авыл җирлегендә төзелеш һәм җирдән файдалану кагыйдәләренә үзгәреш кертү турында»**

____________________ №_____

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге башлыгы Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге Советының 2012 елның 29 ноябрендәге карары белән расланган төзелеш һәм җирдән файдалану кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турындагы мәгълүматны тыңлаганнан һәм фикер алышканнан соң, прокурорның 2016 елның 02-08-02-22/16 , №22 протестына бәйле рәвештә, Яңа Кырлай авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен әзерләү комиссиясе бәяләмәсен һәм Яңа Кырлай авыл җирлеге Советы тарафыннан 15.08.2016 елда уздырылган гавами тыңлаулар нәтиҗәләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Яңа Кырлай авыл җирлеге Советы 29.11.2012 №22 карары белән расланган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару һәм Яңа Кырлай авыл җирлеге кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 30 статьяның 1.2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« 1.2 Җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан рөхсәт ителгән файдалануның беренчел параметрлары:

**Участок күләме:**

Участокның минималь күләме - 1000 кв.м.

Участокның максималь күләме - 2500 кв.м.

**Төзелешләрнең биеклеге:**

Төп корылмадагы катларның иң чик саны - 3 кат (мансар катын да кертеп);

Төп төзелешнең иң чик биеклеге - 10 м;

ярдәмче биналар катларының иң чик саны - 1;

Ярдәмчел корылмаларның иң чик биеклеге - 3,5 м (яссы түбәле), 4,5 м (скат түбәле, тимераякта биеклек).

Коймаларның максималь биеклеге - 2,0 м.

**Төзелеш коэффициенты:**

Йорт тибындагы төзелеш коэффициенты - 0,2

Ябылган йортларда төзелеш коэффициенты - 0,3

Күрше участоклардагы урамнардан һәм корылмалардан минималь ераклыклар: урамнарның кызыл сызыгыннан алып торак йортка кадәр - 5 м, юлларның кызыл

сызыгыннан алып торак йортка кадәр - 3 м;

күрше участок чикләреннән алып торак йортка кадәр - 3 м;

торак бина тәрәзәләреннән алып күрше участокта урнашкан хуҗалык корылмаларына кадәр - кимендә 10 м;

кишәрлек чигеннән алып хуҗалык корылмаларына кадәр - 1 м;

бәдрәфтән күрше йортның стенасына кадәр (үзәкләштерелгән канализация булмаганда) кимендә 12 м;

бәдрәфтән (үзәкләштерелгән канализация булмаганда) су белән тәэмин итү чыганагына кимендә 25 м;

1)

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керүен билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Яңа Кырлай авыл җирлеге башлыгы Г.Г.Сәфәров